УДК 82-94=512.145

# ТӘФКИЛ АГА БИКЧӘНТӘЕВ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

***Л.Ш. Дәүләтшина***

*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*tafkilevna@mail.ru*

Язмада 1943–1944 елларда Бөек Ватан сугышында булган Тәфкил Бикчәнтәевның сугыш көннәре турында истәлекләре тәкъдим ителә. Истәлекләр Җиңүнең 60 еллыгы уңаеннан һәм мәктәп балаларына атап язылган. Истәлекләрдә нindидер нечкәлекләр, хис-тойгылар бик чагылмый; автор, киресенчә, иң төп, үзе бик мөһим дип санаган моментларны гына яктырта.

Язманың структурасы да уйланган: кереш өлешендә автор бөек сугышта җиңүнең кыйммәтен, татар халкының җиңүгә керткән өлешен зурлап искә ала. Язманың бу өлеше өндәмә теле белән язылган. Аннан автор армиягә алынуы, Суслонгер лагерында булуы, Икенче Балтыйк фронтында сугышка керүе турында яза. Язманың бу өлешендә инде аның үзәгенә үткән вакыйгалар искә алына.

Язмалар гади татар авылы баласының сугыш афәтен күрүе, шулай булуга карамастан, ныклы тормыш коруы турында бәян итә.

**Төп төшенчәләр:** Бөек Ватан сугышы, истәлекләр, Суслонгер лагеры, Тәфкил Бикчәнтәев

**Сылтама ясау өчен:** Дәүләтшина Л.Ш. Тәфкил ага Бикчәнтәев истәлекләре // Историческая этнология. 2021. Т. 6, № 1. С. 171–176. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.171-176

Тәфкил Дәүләтша улы Бикчәнтәев (1925–2014), әти ягыннан минем бабай, Бөек Ватан сугышына кагылышлы истәлекләрен 2005 ел башында, Җиңүнең 60 еллыгы якынлашкан көннәрдә яза. Сәбәбе – мәктәптә укучылар белән очрашу көтелә. Шул очрашуга әзерлек йөзеннән ул истәлекләрен теркәп куя. Истәлекләр гади дәфтәргә язылган, теле төзек, диалекталь сүз-формалар юк диярлек. Дәфтәр минем гаилә архивында саклана.

Тәфкил ага Бикчәнтәев Яшел Үзән районының Айдар авылында туып, үсеп, укып, гомер буе шунда хезмәт куйган кеше. Атасы Дәүләтша авылда мулла булып тора; Тәфкил үзе счетовод, бухгалтер булып эшли. Аның авылдан чыгып китүе дә сугышка алыну белән генә бәйле.

Сугыш бетеп 60 ел узгач язылганга, бу истәлекләрдә нindидер нечкәлекләр, хис-тойгылар бик чагылмый; автор, киресенчә, иң төп, үзе бик мөһим дип санаган моментларны гына яктырта.

Язманың структурасы да уйланган: кереш өлешендә Тәфкил ага, пафоска бирелеп, бөек сугышта җиңүнең кыйммәтен, татар халкының

җиңүгә керткән өлешен зурлап искә ала. Язманың бу өлеше өндәмә теле белән язылган. Аннан автор армиягә алынуы, Суслонгер лагерында булуы, сугышка керүе турында яза. Язманың бу өлешендә инде аның үзәгенә үткән вакыйгалар искә алына.

Язмалар гади татар авылы баласының сугыш афәтен күрүе, шулай булуга карамастан, ныклы тормыш коруы турында бәян итә.

Совет халкы һәм аның кораллы көчләренең 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында җиңүенең 60 еллыгы якынлаша. Фашист армиясен тармар иткән һәм күп илләргә азатлык алып килгән Совет солдатларының куркусыз батырлыгы мәрмәрдә һәм дә бронзада мәңгеләштерелгән. Немец-фашист басып алучыларына каршы Бөек Ватан сугышында совет халкының җиңеп чыгуы кешелек тарихының мәңге онытылмас сәхифәләреннән берсе. Бу сугышта яңа җәмгыять төзелеше тарафыннан тудырылган совет кешесенең какшамас ныклыгы, бөек патриотик хисе ачык күренде. Ватаныбызга бөтен дөнья алдында дан китергән бу тарихи җиңү, илебез халыкларының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыгы нәтиҗәсендә яулап алынды. Күп милләтле илебезнең башка халыклары белән берлектә татар халкы да үз Ватанының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшүчеләр сафына басты. Дошманны җиңүгә үзеннән керткән өлеш белән татар халкының чыннан да горурланырга хакы бар. Хәтер китапларында һәм дә һәйкәлләр арасында, кешеләр күңелендә һәлак булган совет сугышчылары турында сүнмәс хәтер аерым урын алып тора.

Мактау һәм дан аларга!

Менә шушы 1941–1945 елларда 1418 көн дәвам иткән кан коюлы сугышта минем дә өлешем булды. Әлбәттә, сезне минем, сугыш ветеранының, ватан сугышында булуы уызыксындыра. Мин үзем Бикчәнтәев Тәфкил Дәүләтша улы 1925 елның 31 июлендә Айдар авылында туган. 1940 елда Күгеш сигезъеллык мәктәбен тәмамладым, аннан соң колхозда эшләдем. 1943 елның 6 гыйнварында безне хәрби хезмәткә алдылар. Ул вакытта Татарстан хәрби комиссариаты берничә җиргә бүленгән иде, мәсәлән, Буада, Бөгелмәдә, Минзәләдә һәм Әгерҗедә. Менә безне инде Буага алып киттеләр, анда 12 көн булдык. Бу чорда инде, әлбәттә, тик кенә яткырмадылар, хәрби хезмәткә өйрәттеләр.

Шуннан соң әшәкелеге белән бөтен Советлар Союзына мәгълүм булган күрше Мари республикасының Суслонгер лагерена алып бардылар. Без Айдардан өч кеше: мин, Абзалов Габдулла, Хәлилов Әхмәдулла; Тугайдан Мөхтәрев Галиәхмәт булдык. Күпчелек Апас, Чүпрәле районы егетләре иде. Менә шунда безгә искереп, таушалып беткән җыртык хәрби киемнәр кидереп 133 нче запастагы полк, танкка каршы атарга өйрәтү ротасына урнаштырдылар.

Бу Сулонгер-Сурок бригадасының командиры полковник Кальный. Безнең полк командиры подполковник Петенко, штаб начальнигы капитан Парловоский, батальон командиры лейтенант Дунаевский, замы лейтенант Тропинов, политчасть буенча зам старший лейтенант Евланов. Днепров, Абрамов, Щербинин взвод командирлары. Бу рота урнашкан иде бүрәнәдән корып эшләнгән зур землянкада. Яту урыннары ике катлы такта сәндерәләр булып, каен чыбыгыннан үрелгән маталар, бер мендәр, бер одеялдан гыйбарәт иде. Өскә ябыну һәм аска җәю өчен шул одеял һәм өстәге шинель булды, башка нәрсә юк. Мич урынына землянканың ике башына ике 200 литрлы мичкә куелган, ул бертуктаусыз яна иде. Әле аның офицерлар бүлмәсе һәм кызыл почмагы да бар иде. Менә шунда без 1943 елның 14 февралендә хәрби ант бирдек. Аннан соң монда менә Күгеш авылыннан Хуҗин Гусман башка ротага килде һәм ул снайперга укырга китте. Күгештән Хәсәнов Габдрахман маршовый ротага чыгарылган иде сугышка китү өчен.

Бу Суслонгерда без иртән зарядкага торгач, ягарга һәм землянкалар корырга күтәреп бүрәнә ташый идек. Аннан соң 6 км дагы стрельбищега җәяү барып кайткач, тагын агач ташу эшен башкара идек. Кысырык крышалы булмаган түбәсе бар иде. Столовойда ашаттылар. Көнгә чиле-пешле 600 г икмәк бирделәр, консерва савытларыннан җыеп ясалган савытларда аш бирәләр иде. Ашта 3–4 бөртек йомры бодай, 2–3 [кисәк] турлаган бәрәңге, 1–2 кисәк туралган яшел помидор була иде. Азрак ашта май булса да, аның итен без күрмәдек. Бу калай аш савытларын Апас авылыныкы Насретдинов Хәйретдин ясап утыра иде. Менә шунда инде бик күп кешеләр авырды, ачтан үлделәр, кайсыберләре мылтык мае щелчь эчеп һәм башкача үлделәр.

Әле март аенда ботинка биргәннәр иде, апрель аенда аны алыштырып яңадан киез итекләр бирделәр, аны кич мичкәдән эшләнгән мичләрдә алмашка төне буе киптерә идек. Бу нәкъ немецларның концлагерына охшашлы бер хәрби часть иде. Солдатка тиешле продукцияне ашатмыйча боздырып, черетеп бетергәннәр. Анда бездән соң оборона министрлыгыннан комиссия килеп, бик күп җитәкчеләрне хәрби трибунал хөкем иткән булса кирәк. Без анда 3 ай артыграк булдык. Бу вакыт эчендә безгә ашарга авылдан 2 мәртәбә ризыклар алып килделәр. Авылдан ашарга алып килмәсләр, безгә дә, белмим, нәрсә булган булыр иде.

Менә шуннан инде апрель ахырларыннан Иваново өлкәсенең Гороховец лагерыннан килгән бер Киселев фамилияле майор безне стройга тездереп үзе сайлап алып китте. Бу 52 стрелковый учебный полк иде. Барып җиткәч, безне мунчалар кертеп яңа киемнәр кидерделәр, бер-беребезне танымас булдык. Бирдә казармаларда бик яхшы аерым койкалар һәм ашау да бик яхшы иде. Бу Гороховецта 6 ай укыганнан соңында сержант званиесы биреп, башка частька җибәрделәр. Монда мин 85 нче гвардия дивизиясенең 253 нче укчы полкында отделение командиры булып хезмәт иттем. Ә инде 1944 елның гыйнвар аенда без сугышка кердек. Бу вакытта

мин рота командирының җәяүле элемтәче идем. Бу ротада күбесе олы кешеләр һәм сугышка икенче-өченче мәртәбә керүчеләр иде. Бу фронт Икенче Балтыйк буе фронты булып, командующий армия генералы Еременко иде.

Дивизия командиры калмык милләтеннән генерал-майор Городовиков, полк командиры подполковник Гришин, комбат старший лейтенант Сергеенко, рота командиры старший лейтенант Колбасин иде. 1944 елның 16 гыйнварында телефон кабеле өзелгәч, аны ялгарга ике солдатны җибәрделәр, алар икесе дә һәлак булды. Аннан соң, мин җәяүле элемтәче булсам да, комрота тагын бер солдат белән мине җибәрде. Шулай да без кабельне ялгадык, минем иптәш үлде, снайперлар аткан булса кирәк. Шуннан кайткач мине «За боевые заслуги» медале белән бүләкләгәннәр иде.

Аннан соң взвод командиры һәлак булгач, 29 гыйнварда миңа лейтенант чины биреп, 2 нче взвод командиры итеп билгеләделәр.

Псков өлкәсенең Великие Лукидан киткәч Алешкино, Скопино дигән авыллар өчен каты сугышлар булды. Мин шунда 1944 елның 2 февралендә авыр җәрәхәтләндем, сул кулым ике җирдән һәм дә аягым җәрәхәтләнде. Һәм мине Кызыл йолдыз ордены беләк бүләкләгәннәр иде. Ләкин бу орден-медальне мин алмаган. Бу сугышта ике взвод командиры һәлак булганын ишеттем. Командир роты да җәрәхәтләнеп, безнең госпитальгә кайтты, һәм полк командиры Гришин да җәрәхәтләнгән иде. Аларны ат белән алып кайттылар. Комрота бүләкләү документларын замполитка калдырырга дигән иде, эзләтергә җибәреп караган идем, Подольскийга җибәрегез диеп җавап килде. Шуннан соң бер җиргә дә язмаган.

Минем белән Апас районынң Олы Күккүз авылыннан Шәфигуллин Габдулла исемле егет тә җәрәхәтләнде. Аның җилкәсенә осколок тигән, хәле авыр иде. Без беребезгә беребез булышкалап, кыр госпиталенә кайтып егылдык. Безгә сугыш кырында Миловидов фамилияле санинструктор беренче ярдәм күрсәтте. Моннан палаткаларда урнашкан полковой госпитальгә килдек. Анда коралларны тапшырып, җәрәхәтләрне яхшылап чистартып бәйләп, тылдарак булган госпитальгә озаттылар. Аннан соң күп госпитальләрдә булып, соңыннан Ярославль өлкәсенең Тутаев районы Константиновка бистәсендәге 3 этажлы 4926 номерлы эвакогоспитальгә килеп җиттек. Бу госпитальдә 4 айга якын дәваланып, соңында хәрби хезмәткә яраксыз булып авылга кайттым.

Кайткач, Күгештә сельпо бар иде, шунда эшкә урнаштым. Бер үк вакытта Айдар башлангыч мәктәбендә военрук булып эшләдем. Бу вакытта военкомат линиясе буенча Күгештә оештырылган штабта шушы күрше алты авылның солдатка китәр вакыты җиткән яшьләрне хәрби-патриотик өйрәтеп, армиягә озата идек. Анда 1927–1928 елда туган яшьләр иде, мин взвод командиры булдым. Мине военкомат хезмәткәре итеп хисаплап, башка хәрби хезмәткә алмадылар.

Шуннан соң сугышлар туктады. Мине 1948 елда Айдар авылына «Игенче» колхозына бухгалтер итеп алдылар, колхозлар берләшкәч тә 22 ел буе баш бухгалтер булып эшләдем.

Фронтта бергә җәрәхәтләнгән Апас егете Шәфигуллин белән очрашып йөрдек, ул Яшел Үзән шәһәрендә ЦСУ инспекторы булып эшләде һәм 2002 елда вафат булды.

Хәләл җефетем Әминә белән 1949 елның ноябрь аенда өйләнешкән, 56 ел яшибез. 4 кыз, 1 ир бала тәрбияләп үстергән. 6 онык, 2 оныкчык бар.

**Автор турында белешмә:** Дәүләтшина Лилия Шамил кызы – өлкән фәнни хезмәткәр, Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты (420015, Пушкин ур., 56, Казан, Россия Федерациясе); tafkilevna@mail.ru

*Редакциягә керде 02.03.2021* *Кабул ителде 22.03.2021*
*Басылды 21.04.2021*

## MEMORIES OF TAFKIL BIKCHANTAEV

***L.Sh. Davletshina***

*Institute of the Tatar Encyclopedia and Regional Studies*
*of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*tafkilevna@mail.ru*

The article presents the memoirs of Tafkil Bikchantaev, who took part in the Great Patriotic War in 1943–1944. His memoirs were recorded at a much later date in honor of the 60th anniversary of the Victory and were directed to schoolchildren. Therefore, T. Bikchantaev is not carried away by details, emotions, on the contrary, he covers only the moments of the war that he considers the most important.

The text is well-structured: in the introductory part, the front-line soldier recalls the value of Victory in the Great War, the contribution of the Tatar people to the Victory. This part is written in slogan language. Then the war veteran recalls how he was drafted into the army, was in the Suslonger training camp, about the famine, about participation in battles on the second Baltic front and about his injury. In this part of the narrative, long-remembered events are mentioned that deeply touched the author of the memoirs.

In general, the recording of memoirs tells how a simple Tatar village guy saw the war, and how he perceived it.

**Keywords:** the Great Patriotic War, memories, Suslonger training camp, Tafkil Bikchantaev

**For citation:** Davletshina L.Sh. Täfkil aga Bikchäntäev istälekläre [Memories of Tafkil Bikchantaev]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2021, vol. 6, no. 1, pp. 171–176. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.171-176

**About the author:** Lilia Sh. Davletshina, Senior Research Fellow, Institute of the Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Tatarstan Academy of Sciences (56 Pushkin St., Kazan 420015, Russian Federation); tafkilevna@mail.ru

*Received March 02, 2021* *Accepted for publication March 22, 2021*
*Published April 21, 2021*

## ВОСПОМИНАНИЯ ТАФКИЛЯ БИКЧАНТАЕВА

***Л.Ш. Давлетшина***

*Институт Татарской энциклопедии и регионоведения*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*tafkilevna@mail.ru*

В статье представлены воспоминания Тафкиля Бикчантаева, в 1943–1944 гг. принимавшего участие в Великой Отечественной войне. Т. Бикчантаев записал свои воспоминания по прошествии значительного времени, в честь 60-летия Победы, и адресовал их школьникам. Поэтому он не увлекается подробностями, эмоциями, напротив, освещает только самые главные, важные, на его взгляд, моменты.

Продумана и структура текста: во вступительной части фронтовик напоминает о ценности Победы в Великой войне, о вкладе в нее татарского народа. Эта часть написана лозунговым языком. Затем участник войны вспоминает, как он был призван в армию, находился в учебном лагере Суслонгер, о голоде, об участии в боях на втором Балтийском фронте и о полученном ранении. В этой части повествования упоминаются надолго запомнившиеся события, глубоко задевшие автора воспоминаний.

В целом запись воспоминаний повествует о том, как простой татарский деревенский парень увидел войну и как он ее воспринимал.

**Ключевые слова:** Великая Отечественная война, воспоминания, учебный лагерь Суслонгер, Тафкиль Бикчантаев

**Для цитирования:** Дәүләтшина Л.Ш. Тәфкил ага Бикчәнтәев истәлекләре // Историческая этнология. 2021. Т. 6, № 1. С. 171–176. https://doi.org/10.22378 /he.2021-6-1.171-176

**Сведения об авторе:** Давлетшина Лилия Шамилевна – старший научный сотрудник, Институт Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан (420015, ул. Пушкина, 56, Казань, Российская Федерация); tafkilevna@mail.ru

*Поступила 02.03.2021* *Принята к публикации 22.03.2021*
*Опубликована 21.04.2021*